**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең Камышинка торак пунктында гражданнар җыены үткәрү нәтиҗәләре турында КАРАРЫ**

**21.11.2024** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 21 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең Камышинка торак пунктында теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2025 елда үзара салымны 600 (алты йөз) күләмендә билгеләргә һәм җыелган сумманы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгына элементлар өстәү)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 38 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 27 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 19 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 8 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең Камышинка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең Камышинка торак пунктында теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2025 елда үзара салымны 600 (алты йөз) күләмендә билгеләргә һәм җыелган сумманы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгына элементлар өстәү » - кабул ителгән.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында (Поручик авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Поручик авыл җирлеге башлыгы И.И.Хаджаева